# ЧИШМӘ БАШЫ




Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» МБМББУ, февраль, 2026 ел № 14

*Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы*

## *Газетаның сәхифәләре:*


1. *Бакчабызда 23 февраль – Ватанны саклаучылар көне.*
2. *Без - Җәлил оныклары.*
3. *Сәламәтлек көне.*
4. *Түбәдән кар төшерер чак.*
5. *Дети рисуют Защитника Родины.*
6. *21 февраль - Халыкара Туган тел көне.*


**Баш мөхәррир:**
**балалар бакчасы мөдире**
**Мостафина Р.Г.**
**Мөхәррир урынбасарлары:**
**музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф.**
**тәрбиячеләр: Хөсәенова Р.Р.,**
**Җәләлиева А.Г., Шәкүрова Р.С.,**
**Хөсәенова В.В.**

«Ватанны саклаучылар көне»
уңаеннан бакчабызга балаларның әтиләрен,
бабайларын кунакка чакырдык.

Аларга багышлап балалар матур шигырьләрен, җырларын башкардылар, матур биюләрен бүләк иттеләр.

Бәйрәмнең иң күңелле өлеше – ул әтиләрнең 2 командага бүленеп ярышулары булды. Тапкырлар һәм батырлар командаларында 3әр әти кеше көч сынашты. Самолет ясап кыршау эченнән чыгару, тизлеккә балаларны киендерү, җиләк-җимешләрне тәлинкәгә матур итеп кисеп кую һәм башка шундый күңелле ярышлар үткәрелде.

Ярышта катнашырга теләген белдергән Хөсәинов Раилгә, Гафиуллин Илнарга, Галявиев Ильяска, Загидуллин Айратка, Хайретдинов Марсельгә һәм Низамиев Айдарга рәхмәтебезне белдерәбез.

Бәйрәм бик күңелле узды. Алдагы бәйрәмнәрдә дә шулай очрашырга язсын!







## Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулу уңаеннан балалар белән кызыклы әңгәмә уздырдык.

Бөек татар шагыйренең якты, кызыклы, әмма шул ук вакытта авыр язмышы турында сөйләштек. Ул кечкенәләр өчен дә бик күп шигырьләр иҗат иткән шагыйрь. Балалар белән М.Җәлилнең тормыш юлын, аның үлмәс иҗатын тагын бер кат искә алдык. Бергәләшеп җырлы-биюле уеннар уйнап, шигырьләр сөйләп, җырлар җырладык. Очрашу ахырында авылыбызның китапханәсендәге күргәзмә белән танышып чыктык.












## Шушы көннәрдә бакчабызда Сәламәтлек көне узды.

Балалар дөрес тукłануның мөһимлеге турында әңгәмәдә актив катнаштылар һәм җиләк-җимеш, яшелчәләр турында күп кенә яңалыклар белделәр. Мәсәлән, алма витаминнарга бай, кишер күрү өчен файдалы, ә помидор иммунитетны ныгыта. Әңгәмәдән соң балалар спорт залына юнәлделәр, анда төрле төстәге фитболаларда сикерделәр, хәрәкәтләрне һәм җитезлекне координацияләделәр.

Бу бәйрәм балаларга сәламәт яшәү рәвешен аңларга һәм файдалы продуктларны яратырга ярдәм итте.













# Түбәләрдән кар төшерер чак

Кояш торган саен яктырак елмая.

Ә бу - түбәләргә карап йөрер вакыт җитә дигән сүз.

Кышын яуган мул карлар тиздән җиргә шуып төшә башлаячак бит.

«Мөндеш» балалар бакчасында куркынычсызлык чараларын вакытында күреп, бинаның түбәсен кардан чистарту өчен ярдәмгә әтиләр дә килде. Кар бик күп булу сәбәпле, махсус кран да чакыртылды.











Галимов Рүзәл, Әхмәтшин Булат, Камалиев Марсель, Исмагилов Дилүс, Хөсәинов Раил, Хисматуллин Илфир, Гафиуллин Илнар, Гарипов Зөлфәт, Закиров Мәһмүт, Юзаев Динар, Асхадуллин Илшат, Нәбиуллин Наил абыйларга

чиксез рәхмәтебезне белдерәбез.

23 февраль - Ватанны саклаучылар көне уңаеннан, безнең балалар бакчасындагы балалар беллән «Дети рисуют Защитника Родины» исемле акциядә катнашып открыткалар ясадык.

Бу эшне бик яратып, кызыксынып башкардык. Открытканы Ватанны саклаучы солдат һәм көчле хәрби машина - танк рәсеме белән бизәдек. Солдатларга матур теләкләр дә өстәп язып куйдык.

Бу чын күңелдән ясалган открыткалар бик матур килеп чыкты. Открыткаларның безне саклаучы солдатларга, безнең хөрмәтебез һәм рәхмәтебез булып барып ирешүен телибез.













21 февраль - Халыкара Туган тел көне.




Без күпмилләтле илдә яшибез. Һәр халыкның туган теле - аның мәдәнияте, тарихи көзгесе ул. Туган тел көне уңаеннан балалар бакчасында атна дәвамында төрле, эчтәлекле чаралар үтте. Алар балаларда туган телгә кызыксыну, хөрмәт уяту, мәхәббәт тәрбияләү максаты белән оештырылды. Шуларның кайберләре: Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулу уңаеннан балалар белән авылыбызның китапханәсендә булдык, күргәзмә белән таныштык, кечкенәләр төркеме белән М.Җәлил әкиятләрен укыдык, зурлар төркеме белән татар халык уены «Түбәтәй» уйнадык, татар композиторларының әсәрләре белән таныштык, кечкенәләр төркеме балалары белән курчак театры уйнадык.




